| | | |
|---|---|---|
| М Э Р<br>ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ<br>ХАКИМЕ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**28.03.2017** | Зеленодольск ш. | **КАРАР**<br>**№ 02-03-03** |

Рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт алу мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Саляхова М.К. мөрәҗәгатен карап, рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт алу мәсьәләсе буенча - җир кишәрлегенең минималь рөхсәт ителә торган мәйданын һәм торак йорт чикләренә кадәр минималь чигенүләрне киметү өчен Зеленодольск шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 14, 15 маддәләре нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан һәм минималь чигенүләрдән 16:49:011704:107 кадастр номеры булган җир кишәрлеге чикләренә кадәр җирнең көнбатыш һәм көнчыгыш ягыннан 0 метрга кадәр чигенүенә рөхсәт алу турындагы мәсьәләне халык тыңлауларына чыгарырга.
2. Билгеләргә:
   2.1. гавами тыңлаулар уздыру датасы һәм вакыты - 2017 елның 03 мае, 16.00 сәгатьтә;
   2.2. гавами тыңлаулар уздыру вакыты - 1 көн;
   2.3. гавами тыңлаулар уздыру урыны - Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорты, 405 каб.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына:
   3.1. рөхсәт ителгән төзелешнең һәм минималь чигенүләрнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт алу мәсьәләсе буенча әлеге карар нигезендә 16:49:011704:107 кадастр номеры булган җир кишәрлеге чикләренә кадәр гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.
   3.2. 2017 елның 10 маеннан да соңга калмыйча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен бастырып чыгарырга;
4. Рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан һәм җир кишәрлеге чикләренә кадәр минималь чигенүләрдән читкә тайпылуга рөхсәт алу мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр, гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар МБУ «Зеленодольск муниципаль районының Архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» да чыгыш ясау хокукы белән гаризалар алу мәсьәләсе буенча ТР, Яшел Үзән ш., Ленин урамы, 41а йорты, №211 каб. (эш көннәрендә 9:00 дән 17:00 сәгатькә кадәр. Тел. /факс: (84371) 4-26-77). Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар бирү вакыты - 2017 елның 23 апреленә кадәр.
5. Ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә 2008 елның 28 июлендәге 108 номерлы Зеленодольск шәһәре Советының

«Зеленодольская правда» 2008 елның 8 августындагы 183 номерлы һәм «Яшел Үзән» 2008 елның 27 августындагы 101 номерлы карары белән расланган ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә үткәрелә.

6. 2017 елның 03 апреленә кадәр әлеге карарны "Зеленодольская правда" газетасында бастырып чыгарырга һәм Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (pravo. tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Зеленодольск шәһәре мэры** **А.В. Тыгин**